| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.06.2026 п.г.т. Алексеевское № 249

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Сахаровка төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең Keче Кызыл Яр авылы, Школьная урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан аерымланган бүлекчәсендә белем бирү эшчәнлеген туктату турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталы авыл җирлеге гражданнары фикерен исәпкә алып (Алексеевск муниципаль районының «Кыр Шонталы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кече Кызыл Яр торак пунктында гражданнар җыенының 23.06.2026 ел,№ 2 беркетмәсе), санитария кагыйдәләре һәм нормалары, янгын һәм террорчылыкка каршы куркынычсызлык таләпләре нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатында

**карар бирәм:**

1. 2026 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Сахаровка төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең Кече Кызыл Яр авылы, Школьная урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан аерымланган бүлекчәсе бинасында (алга таба – «Сахаровка төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУнең аерымланган бүлекчәсе) башлангыч гомуми белем бирүнең төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруны туктатырга.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Сахаровка төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү

учреждениесе (алга таба – «Сахаровка төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ) директоры Т. А. Чилибьевка:

2.1. «Сахаровка төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУнең аерымланган бүлекчәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру туктатылуга бәйле рәвештә, 2026 елның 31 августына кадәр «Сахаровка төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе буенча штат берәмлекләрен кыскарту турында боерык чыгарырга: укытучы – 1,7; пешекче-0,25; җитештерү һәм хезмәт биналарын җыештыручы-0,50; бина һәм корылмаларга хезмәт күрсәтү буенча эшче-0,25;

2.2. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 180 маддәсе таләпләре нигезендә эштән китәргә кимендә ике ай кала штат берәмлекләрен кыскартуга бәйле рәвештә, «Сахаровка төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ хезмәткәрләрен алда торган эштән азат итү турында язма рәвештә кисәтергә.

3. Оператив идарәдән мәктәп бинасын алырга (кадастр (шартлы) номеры 16:05:190301:310), объектның адресы (урнашу урыны): Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Кыр Шонталы авыл җирлеге, Кече Кызыл Яр авылы, Школьная урамы, 12 йорт.

4. Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын туктатырга (кадастр (шартлы) номеры 16:05:190301:15), объектның адресы (урнашу урыны): Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Кыр Шонталы авыл җирлеге, Кече Кызыл Яр авылы, Школьная урамы, 12 йорт.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына https://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**